РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » сентябрь 2017 ел № 38-1

««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Указының 8 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

Порталында Интернет мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә халыкка җиткерелергә тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Мөкерле авыл җирлеге
башлыгы В.П. Носов

ТР Буа муниципаль районының
«11» сентябрендәге 38-1 номерлы
Мөкерле авыл җирлеге Советы карарына
кушымта

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр
бирү тәртибе

1. Бу Тәртип ТР Буа муниципаль районында

муниципаль вазыйфа (депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат);

контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затларга кагыла.

2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында күрсәтелгән вазыйфаи затларның (алга таба - вазыйфаи затлары), аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру процедурасын (алга таба - рәсми сайт) регламентлаштыра, шулай ук, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе билгеләнмәгән булса, массакүләм мәгълүмат чараларына аларны гарызнамәләренә бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү процедурасын регламентлаштыра.

3. Рәсми сайтта түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә:

а) вазифаи зат, аның хатыны ( ире) һәм балигъ булмаган балаларга милек хокукында яки аларның файдалануында булган күчемсез милек объектлары исемлеге, аларның һәрберсенең төрен, мәйданын һәм урнашу илен күрсәтеп;

б) вазифаи зат, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларга милек хокукында булган төр һәм маркалар күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) вазифаи затның, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) оешмаларның устав капиталында җир кишәрлеге, күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, катнашу өлеше, пайлар сатып алу буенча килешүләр төзелгән акчалар алу чыганаклары турында мәгълүмат, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда вазыйфаи затның һәм аның хатынының (тормыш иптәшенең) гомуми кеременнән артып китсә.

4. Рәсми сайтта урнаштырылган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырылган мәгълүматларда күрсәтү тыела:

а) вазифаи затның, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, аталган затларның милек хокукында булган мөлкәте һәм аларның мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында башка мәгълүматлар (бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш) ;

б) вазифаи затның хатыны (ире), балалары һәм гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси мәгълүматлары;

в) вазифаи затның, аның хатыны (ире), балаларының һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка шәхси коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар;

г) вазифаи зат, аның хатыны (ире), балалары, гаиләнең башка әгъзаларының милек хокукында яки алардан файдалануда булган күчемсез милек объектларының кайда урнашуын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар;

д) дәүләт серенә караган яки конфиденциаль булган мәгълүмат.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар рәсми сайтта аларны тапшыру вакыты тәмамланганнан соң 14 эш көне дәвамында урнаштырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны рәсми сайтта урнаштыру җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча белгеч) тарафыннан тәэмин ителә (алга таба – кадрлар хезмәте).

7. Рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматлар, шул исәптән алдагы елларда да:

а)  бетерелергә тиеш түгел;

б) вазифаи затның үз вазифасын биләве чорында ачык керү мөмкинлегендә (рәсми сайтларда урнаштырылган).

8. Вазифаи зат тарафыннан төгәлләнгән мәгълүматны тапшырганда, рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматка төгәлләнгән мәгълүматны тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча, тиешле үзгәрешләр кертелә.

9. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау килгәндә кадрлар хезмәте:

а) запрос килгән көннән алып өч эш көне эчендә аның турында запрос килгән вазифаи затка хәбәр итә;

б) сорау килгәннән соң җиде эш көне дәвамында, әгәр соралган мәгълүмат рәсми сайтта булмаса, әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны бирүне тәэмин итә.

10. Кадрлар хезмәтенең муниципаль хезмәткәрләре әлеге тәртипне үтәмәү, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт серенә караган яки конфиденциаль булган мәгълүматларны ачу өчен җаваплы.